| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.10.2019 Баулы шәһәре № 113

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү буенча гарантияле оешманы билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 190-ФЗ номерлы «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законнарына таянып, Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү буенча гарантияле оешма итеп «Газпром теплоэнерго Казань» «Бавлинский» җаваплылыгы чикле җәмгыятен билгеләргә.

2. Җылылык белән тәэмин итү буенча гарантияле оешма эшчәнлеге территориясе итеп Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен билгеләргә.

3. Әлеге карарны www:pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм www:Bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин